Эссэламv галэйкvм вэ рэхмэтуллаhи вэ бэрэкэтvh, хөрмэтле дин кардэшлэрем, газиз ватандашларым!

Россия Федерациясе моселманнарынын Үзәк диния нәзарәте исеменнән, шәхсән vземнен әтрафымнан сезне мобарәк Ид-әль-Фитр Ураза гаете бәйрәме унаеннан ихлас кvнелемнән тәбрик итәм!

Таннан алып кояш баеганча, Рамазан шәриф ае буе ураза аркылы vз-vзебезнен нәфесләребез белән сугышып, Аллаhы Тәгалә кушканнарын vтәп, тойганнарыннан тоелып, тоннәре жәмәгать белән мәчетләрдә Аллаhынын илчесе Мохәммәд галәйhи сәламнен таравих соннәт гамәлләрен vтәп ике доньянын бәхетенә, сәгадәтенә ирешербез дип, Аллаhы Раббыбыз тарафыннан әжер вә саваб белән бvләкләнербез дип, ныклы ышаныч белән Аллаhы Тәгаләгә тәвәккәл кылып даими рәвештә догада калабыз. Кvп милләтле hәм кvп динле илебез халкына Аллаhы Раббыбыз бәрәкәт hәм сәкинә, ил-коннәребездә тынычлык, иминлек бирсен!

Россия Федерациясе Президентына В.В.Путинга, Мордовия Республикасы Башлыгына А.А.Здуновка, дәvләт тvрәләребезгә Аллаhы Раббыбыз дәvләтебез белән сәяси идәрә итvдә зирәк зиhен, камил акыл, кvркәм холык, унышлар бирсен! Ватанпәрвәрләребезгә, хәрбиләребезгә махсус хәрби операциядә дошманнарыбыз остендә остенлек hәм жинv бирсен!

Барчагызга да зур ихтирам, хэер дога, кайнар сэламлэр белэн,

Мордовия Республикасында Россия Федерациясе мөселманнарынын

Үзәк диния нәзарәты тулы хокуклы вәкиле ***Рафаэль МАНЮРОВ***